**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 елның 18 декабре №16

Бюджетара трансфертларны исәпләү методикасын раслау турында

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль Законының 14 һәм 15 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 һәм 142.5 статьялары, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы « Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан, Татарстан Республикасы « Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына мөлкәт белән идарә итү, аннан файдалану, җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы « Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең милек объектлары реестрларының рәсми сайтларында бастырып чыгару буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру, шулай ук кушымта нигезендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген расларга.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Күгеш авылы, Совет урамы, 17 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Күгеш авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Күгеш авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **А.А.Гатауллин**

Татарстан Республикасы
Яшел Үзән муниципаль районы
Күгеш авыл җирлеге Советының 2020 елның
18 декабрендәге 16 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертларны исәпләү методикасы**

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең (алга таба-авыл җирлеге) мөлкәт белән идарә итү, алардан файдалану, алар белән эш итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен, Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайтында җирлек мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына җирлек вәкаләтләренең югарыда күрсәтелгән өлешен үтәүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен бирелә.

Җирлек вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру, мөлкәт (шул исәптән җир кишәрлекләре) белән эш итү, җирлекнең рәсми сайтларында җирлек мөлкәте объектлары реестрларын, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлекләрен бастырып чыгару буенча бюджетара трансфертлар катгый максатчан билгеләнешкә ия.

Трансфертлар катгый максатчан билгеләнешкә ия һәм әлеге методиканың 1 пунктында күрсәтелгән максатларга тотыла.

Җирлек тарафыннан районга тапшырыла торган трансфертларның күләме
W= (R*K)/100 формула буенча билгеләнә, кайда

W - Татарстан Республикасы «Яшел Үзән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына трансфертларның еллык күләме
R – «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтнең гомуми күләменә карата, Яшел Үзән муниципаль районының 23 (егерме өч) муниципаль берәмлегенең гомуми милкенә карата процент чагылышында.

R= (U / V)*100, кайда
U - муниципаль берәмлек милкендә булган мөлкәт объектларының гомуми саны
V - Яшел Үзән муниципаль районының 23 (егерме өч) муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәт объектларының гомуми саны
К - әйдәп баручы белгеч (муниципаль хезмәткәр) исәпләп чыгарган хезмәт хакы фонды)